| ГЛАВА БИЛЯРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БИЛӘР АВЫЛ СОВЕТЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12. 2019 с. Билярск № 27

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе нигезендә

**карар кылам:**

1. 2019 елның 21 декабрендә 14 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге Биләр авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2019 елның 21 декабрендә 16 сәгать 00 минутта Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Биләр урта мәктәбе бинасында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Биләр елгасының сул як ярында яшәүче гражданнарны Җыенының беренче этабында катнашу өчен билгеләргә.

Биләр елгасының уң як ярында яшәүче гражданнарны Җыенының икенче этабында катнашу өчен билгеләргә.

4. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

2020 елда Биләр авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 1 Төркем инвалидлардан, көндезге укудагы студентлардан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнардан, 4 һәм аннан күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту);

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм төзү;
- торак пунктларда урамнарны яктырту;
- күмелгән урыннарны карап тоту һәм төзекләндерү;
- техниканы карап тоту (трактор, килешү буенча хезмәт хакы);
- контейнер мәйданчыклары төзү;
- торак пунктлардагы агач коймаларны төзекләндерү (капиталь ремонтлау)

«ӘЙЕ» «ЮК»

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр авылы, Калинин урамы, 3 нче йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән; Татарстан Республикасы, Алексеевск муниципаль районы, Биләр авылы, Ленин урамы, 6 нчы йорт адресы буенча; Биләр авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы** **Г.Г.Хәбибуллин**